2005 ел, 29 декабрь 661

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль законны һәм «Муниципаль берәмлекләргә җирле үзидарә әһәмиятендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен дәүләтнең матди ресурсларын һәм дәүләт субсидияләрен бирү турында» 2005 ел, 30 декабрь, ТРЗ-140 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацындагы “148” санын – “230” санына, “546,2” санын “832,2” санына алыштырырга;

карарның 2 нче пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

3 нче пункттагы “биш урынбасарын” дигән сүзләрне “алты урынбасарын” дигән сүзләргә алыштырырга;

“Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы территориаль органнарының Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләре карамагына тапшырыла торган штат саны” дигән кушымтаны бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

карарның 5 нче пунктындагы “2005 елга Татарстан Республикасы бюджетында” дигән сүзләрне “2006 елга Татарстан Республикасы бюджетында” дигән сүзләргә алыштырырга;

карарга түбәндәге эчтәлектәге 4, 5 нче пунктларны өстәргә:

«4. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы территориаль органнарының 86 берәмлек штат санын бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре карамагына тапшырырга.

5. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына норматив хокук актларын бу карарга яраклаштыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.»;

4, 5, 6, 7 нче пунктларны шул ук эзлеклелектә 6, 7, 8, 9 нчы пунктлар дип санарга.

карарга әлеге карарга теркәлгән редакциядә бәян ителгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны өстәргә

Татарстан Республикасы
Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов

F:\KARAR\3572001a7.doc